СОВЕТ
НОВОКИШИТСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Дружба, д. 100а, с. Новый Кишит,
Арский муниципальный район, 422034

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢА КИШЕТ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Дуслык урамы, 100а йорт, Яңа Кишет авылы,
Арча муниципаль районы, 422034

Тел. (84366)55-4-42, факс (84366)55-4-42. E-mail: Nvk.Ars@tatar.ru

# КАРАР

**“30” апрель 2020 ел** **№49**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кишет авыл җирлеге Советына депутатлар сайлауларын үткәрү өчен бермандатлы сайлау округлары схемасын раслау турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясы, 2007 елның 7 маендагы 21-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 26 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кишет авыл җирлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кишет авыл җирлеге Советына депутатлар сайлау өчен бермандатлы сайлау округлары схемасын расларга (кушымта).

2. Яңа Кишет авыл җирлеге Советының 8 май 2015 елның 12 номерлы «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кишет авыл җирлеге Советына депутатлар сайлауларын үткәрү өчен бермандатлы сайлау округлары схемасын раслау турында» карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районы рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru), гражданнар күпләп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларында ТР, Арча районы, Яңа Кишет авылы, Дуслык урамы, 100а йорты; Иске Кишет авылы, Г.Сафиуллин урамы, 26а йорты; Кышкар авылы, Яңа урам, 125 йорт; Симетбаш авылы, Үзәк урам, 19а йорты адреслары буенча урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кишет авыл җирлеге Советы рәисе Т.А. Арслановка йөкләргә.

Яңа Кишет авыл җирлеге башлыгы Т.А. Арсланов